
# Сыйныф сәгате




**КАЗАН ШӘҺӘРЕ СОВЕТ РАЙОНЫ
АБДУЛЛА АЛИШ ИСЕМЕНДӘГЕ 20 НЧЕ ГИМНАЗИЯ
БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФ УКЫТУЧЫСЫ
МИНИМУЛЛИНА А.Х. ТӨЗЕДЕ**











# БУ РӘСЕМНӘР НИНДИ ӘКИЯТЛӘРДӘН? АЛАРНЫ КЕМ ЯЗГАН?



- Абдулла Алиш 1908 нче елның 15 нче сентябрендә хәзерге Спас районы Көек авылында туган . Бабасы Нурулла мулла булган , ә әтисе Габделбари хуҗалык эшләре белән шөгельләнгән –иген иккән , умарта караган. Әнисе Газизә укымышлы булган , шигырь һәм бәетләр чыгарган. 8 яшьтә Абдулланы әтисе үзләреннән 15 км ераклыктагы авылга мәдрәсәгә биргән. Аннан педагогия техникумы каршындагы мәктәпне тәмамлый.
1927нче елда Казанга килә , җир төзү техникумында укый. Шунда алган һөнәре буенча эшли. 1937нче елдан Бөек Ватан сугышы башланганчы “ Пионер каләме” ( “Ялкын”) журналы редакциясендә, радиокомитетта эшли. Педагогия институтында укый. Иң күп язган еллары була бу. Алишны балаларның сөекле язучысы иткән әсәрләр- әкиятләр. 20 дән артык әкият яза. Аларны “Нечкәбил” , “Әкиятләр” , “Ана әкиятләре” исемнәре белән бастырып чыгара.











- Сугыш башлангач , 1941 нче елда фронтка китә , разведчик була. Чолганышта калып, фашистлар кулына әсир төшә. Берлин төрмәсендә Муса Җәлил белән очраша.
- 1944 нче елның 12 нче августында фашистлар Алишны үтерәләр. Ләкин әдипнең гомерен үлем чикләми. Абдулла Алиш , көрәштәше Җәлил кебек үк, туган халкы белән бергә киләчәккә горур атлап бара.

- . “Сыерчык белән чыпчык” кайсы әкият геройлары? _(“ Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык”)_
- 2. “Бу нинди боерык ? Нәрсә ул койрык ? “ бу җөмләләр кайсы әкияттән? _(“ Койрыклар”)_
- 3.”Кайгырма , туганкай, йомшак Куянкай, кызыңның аягын бик тиз төзәтеп була.” _(“Куян кызы”)_
- 4. “ Серең эчендә торса , йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр.” _(“Сертотмас үрдәк”)_




# “Каз белән Аккош” әкиятен искә төшерик.

..... үзенең бәбкәсен төрлечә сыйлап караган: тәмле-тәмле балыклар, яшел бакалар, татлы кыскычлар тотып китерә икән. Баласы, үзе зур булса да, кулына кашык тотып ашамаган, әнисенең ашатуын көткән. Ашау аңа бик зур эш булган. Ашарга-эчәргә тотынса, ул тәмам йөдәп беткән.
Ә дуга муен — ..... баласы кыстатып та тормый, кашыкны үзе тотып, азыкны кат кат чәйни, тәмле итеп ашый икән. Вакытында йоклый, вакытында һавага чыга, уйный, шуңа күрә алма кебек кызарып, матур булып үсә икән.



“Чукмар белән Тукмар” әкиятендә А.Алиш безне нинди булмаска өйрәтә?









**“Куян кызы” әкиятнен персонажларын санап бирегез.**




2001нче елда туган авылы Көектә Абдулла Алишка һәйкәл салынды. Көектә , Казанның Балалар иҗаты үзәгендә,55 мәктәптә аңа багышланган музейлар эшли. 1990 нчы елда ул 1нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән үлгәннән соң бүләкләнде. Менә кем булган ул - Абдулла Алиш.